| | | |
|---|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2025 п.г.т. Алексеевское № 300

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гражданнардан сорашып белешү турында Нигезләмә хакында»2009 елның 21 гыйнварындагы 25/612 номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 21.01.2009 ел, №25/612 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гражданнардан сорашып белешү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 бүлекнең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турында карар Алексеевск муниципаль районы Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен Алексеевск муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтын файдаланылырга мөмкин. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турында Алексеевск муниципаль районы Советының норматив хокукый актында:

1) сораштыруны үткәрү датасы һәм сроклары;

2) Сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең формасы;

5) сораштыруда катнашучы Алексеевск муниципаль районында яшәүчеләрнең минималь саны;

6) сораштыру үткәрелгән очракта сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе Алексеевск муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып бирелгән.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары, Совет рәисе урынбасары Г.В. Беловага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. А. Демидов**